СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д. 1А, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яңа урам, 1А йорты, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

Яңа Кишит авыл җирлеге Советы

**КАРАРЫ**

**10 сентябрь 2024 ел** **№105**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишит авыл җирлеге Советының 2023 елның 29 ноябрендәге 89 номерлы "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, «салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Яңа Кишит авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишит авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 29.11.2023 №89 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   « 4) 2025-2027 еллар чорына карата 1,2 процент:
   гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслары) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән биналар;».
2. 2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кишит авыл
җирлеге башлыгы Ф.И.Ахмадуллин